**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 3** **22.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлеге составына керүче Кәтем авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә, "2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе буенча граҗданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, укучыларның көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә киметергә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны юнәлтү турында:

- Кәтем авылы урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәтем авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Кәтем авылында юлларны кардан чистарту, (килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәтем авылында «Сабантуй» һәм « Яңа ел» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу;)
- Кәтем авылы территориясен җәйге вакытта чабып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

"РИЗА" "КАРШЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 104 кеше кергән, халык җыенында катнашучылар саны 65 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 65 кеше тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы составына керүче Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем авылында узган халык җыенын үтте дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре- дөрес.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүртйөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарының һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә билгеләргә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Кәтем авылы урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәтем  авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Кәтем авылында юлларны кардан чистарту, (килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәтем авылында «Сабантуй» һәм « Яңа ел» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу;)
- Кәтем авылы территориясен җәйге вакытта чабып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу)турындагы карары кабул ителде.

3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.  һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Кәтем  авылы, Кәтем  ур. 1 а йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы: И.М.Мөхәмәтҗанов